Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Кукмара шәһәре Советы
Карары

18 октябрь, 2019 ел №24

Гомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында гомуми файдалану парковкалары оештыру турында

Юл хәрәкәтен оештыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә парковкалар булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2007 елның 8 ноябрендәге № 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында», 1995 елның 10 декабрендәге № 196-ФЗ «Юл хәрәкәте иминлеге турында» федераль законнары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Уставы нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар чыгарды:

1. Расларга:

Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районыныңгомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, булдыру һәм аларны куллану Тәртибе.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Кукмара шәһәре Мэры С.Д. Димитриев

Кукмара шәһәре Советының
18 октябрь, 2019 ел
№24 карарына
кушымта

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районыныңгомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, булдыру һәм аларны куллану Тәртибе.

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының гомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, булдыру һәм аларны куллануның әлеге Тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 1995 елның 10 декабрендәге № 196-ФЗ «Юл хәрәкәте иминлеге турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2007 елның 8 ноябрендәге № 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законнары, Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, Татарстан Республикасы законнары һәм хокукый актлары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Уставы нигезендә эшләнде.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының гомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, булдыру һәм аларны куллану процедурасын билгели.

3. Тәртиптә кулланыла торган төп терминнар һәм төшенчәләр «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында бирелгән мәгънәдә кулланыла.

Тәртипнең максатлары өчен шулай ук түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

- гомуми файдаланудагы парковка – чикләнмәгән даирәдәге затларга файдалану өчен билгеләнгән парковка (парковка урыны);
- түләүле парковка – түләүле нигездә файдаланыла торган гомуми файдаланудагы парковка;
- түләүсез парковкалар – транспорт чараларын вакытлыча урнаштыруны оештыру өчен билгеләнгән тәртиптә махсус җиһазландырылган, парковкадан файдаланган өчен транспорт чаралары хуҗаларыннан түләү алынмый торган парковкалар;

- парковкадан (парковка урыныннан) файдаланучы – парковкада (парковка урынында) транспорт чарасын урнаштыручы зат;

- парковка (парковка урыны) операторы – Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә конкурс нигезендә сайлап алынган Кукмара шәһәре Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан парковканы оештыру һәм эксплуатацияләү өчен вәкаләтле муниципаль учреждение яки оештыру-хокукый формаларга бәйсез юридик зат, шәхси эшмәкәр;

- түләү җиһазлары (паркомат) – парковкадан (парковка урыныннан) файдаланган өчен түләү алуның 2003 елның 22 маендагы 54-ФЗ номерлы «Акчалата исәп-хисап һәм (яки) түләү карталарыннан файдаланып исәп-хисап ясаганда контроль-касса техникасын куллану турында», 2009 елның 3 июнендәге № 103-ФЗ номерлы «Түләү агентлары тарафыннан башкарыла торган физик затларның түләүләрен кабул итү эшчәнлеге турында» федераль законнар таләпләренә җавап бирә торган техник чарасы.

## 2. Парковкаларны (парковка урыннарын) булдыруның максатлары һәм бурычлары

1. Парковка (парковка урыннары) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының гомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларының үткәрүчәнлек сәләтен һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру максатларында булдырыла.

2. Күп фатирлы йортлар урнашкан планлаштыру структурасы элементы чикләрендә гомуми кулланыштагы территорияләрдә гомуми файдаланудагы парковкаларны төзү турында карар Башкарма комитет тарафыннан территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә, шулай ук гомуми кулланыштагы мондый территорияләр янәшәсендәге җир кишәрлекләрендә урнашкан әлеге күп фатирлы йортларның бүлмәләре милекчеләренең фикерен исәпкә алып кабул ителә. Күп фатирлы йортларның бүлмәләре милекчеләренең фикерен ачыклау һәм исәпкә алу, шулай ук планлаштыру структурасы элементының чикләрен билгеләү муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Күп фатирлы йорт бүлмәләре милекчеләренең гомуми милкенә караган җир кишәрлеге чикләрендә гомуми файдаланудагы парковкаларны төзү турында карар торак законнары һәм җир законнары нигезендә кабул ителә.

3. Парковка (парковка урыны) булдыру белән кызыксынган зат Башкарма комитетка парковка (парковка урыны) булдыру турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Парковка (парковка урыны) булдыру белән кызыксынган зат Башкарма комитетка парковка (парковка урыны) булдыру турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Гаризага парковка (парковка урыны) булдыруның максатка ярашлылыгын нигезләү, түләүле нигездә яки түләү алмыйча парковка (парковка урынын) куллану турындагы тәкъдим һәм парковка (парковка урынын) урнаштыру

проекты теркәлә. Парковканы (парковка урынын) урнаштыру проектында түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) парковка (парковка урыны) чикләрен һәм машина-урын саны күрсәтелгән парковканы (парковка урынын) урнаштыру схемасы;

2) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең гомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлы планының парковка (парковка урыннарын) оештыру урынын билгеләгән фрагменты. Анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- парковкның (парковка урынының) урнашу урыны (адреслы ориентирлар);

- парковканың (парковка урынының) размерлары;

- автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның чикләре;

- кызыл линияләрнең чикләре (кирәкле территориядә булган очракта).

4. Башкарма комитетка кергән парковка (парковка урыны) булдыру буенча кирәкле материаллары булган парковка (парковка урынын) урнаштыру проекты буенча, Башкарма комитет әлеге материаллар кергән көннән алып 10 эш көне дәвамында парковканы (парковка урынын) урнаштыру проектының гамәлдәге законнарга туры килү-килмәвенә бәяләмә әзерли һәм килештерү өчен җибәрә:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең гомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлын үз балансында тотучыга;

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча ЮХИДИ бүлегенә;

- инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр хуҗасына (хуҗаларына).

5. Башкарма комитет парковканы (парковка урынын) урнаштыру проектын ул кергән көннән алып ун календарь көн эчендә килештерә.

6. Башкарма комитет, кергән килешүләрне һәм бәяләмәне исәпкә алып, парковка (парковка урыны) булдыру турындагы гаризаны карый һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- парковка (парковка урыны) булдыру һәм аны түләү алмыйча куллану турында;

- парковка (парковка урыны) булдыру һәм аны түләүле нигездә куллану турында;

- парковка (парковка урыны) булдырудан баш тарту турында.

7. Парковка (парковка урыны) булдырудан баш тарту өчен нигез булып торалар:

- әлеге Тәртиптәге маддәнең 2 нче өлешендә каралган кирәкле документ(лар)ның булмавы;

- парковканы (парковка урынын) урнаштыру проектының Тәртиптәге әлеге маддәнең 2 нче өлешендә каралган таләпләргә туры килмәве;

- тискәре бәяләмә һәм (яки) парковканы (парковка урынын) урнаштыру проектын килештерүдән нигезле баш тарту булу.

8. Парковка (парковка урыны) булдыру турындагы карар Башкарма комитет карары белән рәсмиләштерелә, ул үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

- парковканың (парковка урынының) урнашу урыны (адреслы ориентирлар);

- парковканың (парковка урынының) чикләре, күләмнәре;

- парковкада машина кую урыннары саны;

- оператор муниципаль учреждение булса, парковка (парковка урыны) операторының исеме, яисә парковка (парковка урыны) операторын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү вакыты;

- парковка (парковка урыны) булдыру чаралары.

9. Кабул ителгән карар турында парковка (парковка урыны) булдыру турында гариза белән мөрәҗәгать иткән затка карар кабул ителгән көннән соң 3 эш көне дәвамында язма рәвештә хәбәр ителә.

10. Парковка (парковка урыны) операторын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибе Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

## 3. Парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану тәртибе

1. Парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану түләүле нигездә яисә түләү алмыйча гамәлгә ашырыла.

2. Парковкалардан файдаланучы парковкадан файдалану кагыйдәләре, түләүле нигездә парковкалардан файдаланган өчен түләү күләме, түләү кертү тәртибе һәм ысуллары турында мәгълүмат алырга хокуклы. Парковкалардан файдалану кагыйдәләре Башкарма комитетның хокукый акты белән раслана.

Башкарма комитет түләүле парковкаларны куллана башлаганчы утыз календарь көннән дә соңга калмыйча «Хезмәт даны» («Трудовая слава») газетасында, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге мәгълүматны урнаштыру юлы белән түләүле парковкалар булдыру һәм алардан файдалану турында карар әзерләү турында халыкка хәбәр итә:

1) түләүле парковкалардан файдалану кирәклеген нигезләү, гомуми кулланудагы парковкалардан файдаланган өчен түләү кертү юлы белән хәл ителергә тиешле юл хәрәкәте өлкәсендәге төп проблемалар;

2) түләүле парковкалардан файдалана башлау вакыты;

3) муниципаль берәмлек территорияләрендә түләүле парковкаларның фараз ителгән зоналары;

4) түләүле парковкалардан файдалану тәртибе;

5) парковкалардан файдаланган өчен түләү күләме һәм тәртибе.

3. Парковкада (парковка урынында) парковка операторы тарафыннан мәгълүмат щиты урнаштырыла, анда түбәндәге мәгълүмат күрсәтелә:

- парковканың (парковка урынының) эш вакыты;

- парковка (парковка урыны) өчен түләү күләме (парковка түләүле булса);

- парковка (парковка урыны) өчен түләү кертү тәртибе һәм ысуллары (парковка түләүле булса);

- парковка (парковка урыны) операторының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге исеме, адресы, элемтә өчен телефоннары;

- парковкада (парковка урынында) фотога төшерүнең һәм видеофиксациянең автоматик чараларын куллану турында мәгълүмат;

- парковкадан (парковка урыныннан) файдаланучыларның язмача дәгъваларын кабул итү урыннары турында мәгълүмат.

4. Парковкадан (парковка урыныннан) түләүле файдалану түләү җиһазлары (паркомат) биргән түләү документы нигезендә башкарыла.

5. Парковкада (парковка урынында) буш урын булганда, парковкадан (парковка урыныннан) файдаланучы транспорт чарасын парковкада (парковка урынында) урнаштырырга хокуклы.

6. Парковкадан (парковка урыныннан) файдаланганда парковкадан (парковка урыныннан) файдаланучының бурычлары:

1) Россия Федерациясенең юл хәрәкәте кагыйдәләре һәм Тәртип таләпләрен сакларга;

2) парковкада (парковка урынында) транспорт чарасын юл билгеләре һәм билгеләгән сызыкларга туры китереп урнаштырырга;

3) транспорт чарасын парковкада (парковка урынында) урнаштыру вакытына карап түләүле парковкадан (парковка урыныннан) файдаланган өчен түләү кертергә;

4) түләнгән вакыт үткәннән соң ун минут эчендә парковканы (парковка урынын) бушатырга.

7. Парковка (парковка урыны) операторы түбәндәге функцияләрне башкара:

1) гамәлдәге законнар һәм Тәртип таләпләренә туры китереп, парковка (парковка урыны) оештыра һәм эксплуатацияли;

2) юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын, парковка җиһазларын (түләү җиһазларын (паркоматларны)), мәгълүмат щитларын һәм парковка (парковка урынын) эшләтү өчен кирәкле башка техник чараларны урнаштыра, карап тота, хезмәт күрсәтә һәм саклый;

3) парковка (парковка урыны) территориясен карап тотуны һәм җыештыруны гамәлгә ашыра;

4) парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдаланучыларның парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдаланган өчен түләү кертүен контрольдә тота.

8. Парковкада (парковка урынында) транспорт чаралары хәрәкәтен гамәлгә ашыру тәртибе, транспорт чараларын кую, аларга керү һәм чыгу кагыйдәләре Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре белән регламентлана.

9. Һәр парковкада (парковка урынында) урнашкан машина кую урыннарының гомуми саныннан машина-урыннарның кимендә 10 проценты (әмма 1 машина-урыннан да ким түгел) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә I, II төркем инвалидлары, шулай ук III төркем инвалидлары идарә итә торган транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларын түләүсез кую өчен бүлеп бирелә. Инвалидлар идарә итә торган транспорт чаралары, шулай ук инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртүче транспорт чаралары юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә махсус юл билгеләре һәм (яки) тамгалары белән билгеләнгән урыннарда урнаштырыла. Парковка өчен күрсәтелгән мондый урыннарны башка транспорт чаралары алып торырга тиеш түгел.

10. Түләүле парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдаланган өчен түләү күләме Башкарма комитет тарафыннан түләүле нигездә парковкалардан

(парковка урыннарыннан) файдаланган өчен түләүне исәпләү методикасы нигезендә билгеләнә.

Гамәлдәге законнарны исәпкә алып, парковкалардан (парковка урыннарыннан) түләүле нигездә куллanudан кергән керемнәр Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре бюджетына күчерелә.

11. Парковкадан (парковка урыныннан) файдаланган өчен түләүдән тыш, түләүле парковкадан (парковка урыныннан) файдаланучылардан башка түләүләр алу рөхсәт ителми.

12. Түләүле парковкадан файдаланган өчен түләү алу түбәндәгеләргә карата рөхсәт ителми:

- I, II төркем инвалидлары, шулай ук III төркем инвалидлары идарә итә торган транспорт чараларына һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларына. Күрсәтелгән транспорт чараларында башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы тарафыннан билгеләнгән Тәртип нигезендә бирелгән «Инвалид » тамгасы урнаштырылырга тиеш;

- янгын сагы, полиция, ашыгыч медицина ярдәме, авария-коткару хезмәтләре, хәрби автомобиль инспекциясе эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган транспорт чараларына, шулай ук куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге федераль башкарма хакимият органы, дәүләт сагы өлкәсендәге федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби полициясе, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының тикшерү органнары, федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясендә федераль фельдъегер элемтәсен тәэмин итү өлкәсендә хезмәт ихтыяҗына бәйле рәвештә кулланыла торган махсус функцияләрне гамәлгә ашыручы транспорт чараларына.

13. Дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдә урнашкан түләүле парковкалардан түләүсез файдаланыла:

1) эш һәм шимбә көннәрендә җирле вакыт белән 21 сәгать 00 минуттан 7 сәгать 00 минутка кадәр;

2) транспорт чарасы 15 минуттан да арттык вакытка туктамаган очракта;

3) якшәмбе һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә.

Дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдә урнашкан түләүле парковка хуҗасы әлеге түләүле парковкадан бушлай файдалану вакытының әлеге пункт белән билгеләнгән вакытын арттырырга хокуклы.

14. Парковка (парковка урыны) операторы тарафыннан, килеп туган бәхәсләрне җайга салу максатларында, фотога һәм видеога яздыруның автоматик чаралары ярдәмендә парковкада (парковка урынында) урнаштырылган транспорт чараларының дәүләт теркәү номерлары турындагы белешмәләрне теркәү, җыю, саклау һәм куллануны, парковкадан (парковка урыныннан) файдалану вакытын һәм урынын үз эченә алган парковкадан (парковка урыныннан) файдалану фактларын теркәү башкарыла.

15. Парковка (парковка урыны) операторы, Тәртипнең әлеге маддәсенең 14 нче өлешендә каралган мәгълүматларны саклаганда һәм кулланганда,

күрсәтелгән мәгълүматны өченче затлардан саклау һәм яклау буенча гамәлдәге законнарда каралган барлык чараларны күрә.

## 4. Парковкаларны (парковка урыннарын) куллануны туктату тәртибе

1. Парковканы (парковка урынын) куллануны туктату турындагы карар әлеге маддәнең 2 нче өлешендә каралган нигез(ләр)не раслаган көннән алып 10 эш көне дәвамында карар чыгару юлы белән Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә.

2. Парковкаларны (парковка урыннарын) куллануны туктату турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәренең парковка (парковка урыны) урнашкан гомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлы участогында юл хәрәкәтен оештыру схемасындагы үзгәрешләр;
- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең гомуми кулланыштагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлының машина кую урынын (парковка урынын) урнаштыру белән бәйле үткәрүчәнлеге кимү;
- тиешле территориядә шәһәр төзелеше вәзгыяте үзгәрү;
- машина кую урынын (парковка урынын) алга таба кулланырга мөмкинлек бирми торган гамәлдәге законны бозу фактын ачыклау.

3. Башкарма комитетның парковканы (парковка урынын) куллануны туктату турындагы карарында түбәндәгеләр булырга тиеш:

- парковка (парковка урынын) урнаштыру урыны (адреслы ориентирлар);
- парковканы (парковка урынын) куллануны туктатуга нигезләре;
- парковканы (парковка урынын) куллану туктатыла торган дата.

4. Парковканы (парковка урынын) куллануны туктату турындагы карарның күчермәсе карар кабул ителгән көннән соң 3 эш көне дәвамында парковка операторына җибәрелә.